**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 24 декабрендәге 5334 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы**
**«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 79 еллыгын,**
**Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен**
**бәйрәм итүгә, Яңа ел бәйрәменә, Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның**
**тууына 138 ел тулуга багышланган чараларны, шулай ук**
**«Җиңү варислары»VII ачык хәрби-спорт җыеннарын ачу тантанасын,**
**«Казан марафоны – 2024» халыкара җиңел атлетика чарасын**
**әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында**
**транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм:**

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 79 еллыгын, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен бәйрәм итүгә, Яңа ел бәйрәменә, Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулуга багышланган чараларны, шулай ук «Җиңү варислары» VII ачык хәрби-спорт җыеннарын ачу тантанасын, «Казан марафоны – 2024» халыкара җиңел атлетика чарасын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның

15 августындагы 3366 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 4 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы карарына 4 номерлы кушымта дип санарга;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 79 еллыгын, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен бәйрәм итүгә, Яңа ел бәйрәменә, Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулуга багышланган чараларны, шулай ук «Җиңү варислары» VII ачык хәрби-спорт җыеннарын ачу тантанасын, «Казан марафоны – 2024» халыкара җиңел атлетика чарасын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертелү хакында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә;

2.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карарга кушымта нигезендә Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 24 декабрендәге
5334 номерлы карарына
кушымта

**Яңа ел бәйрәм чараларын әзерләү һәм үткәрү чорында**
**Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап**
**транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2024 елның 19 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2025 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр | С.Хәким урамы буйлап ике якка да (Декабристлар урамы белән кисешкән урыннан Әпсәләмов урамы белән кисешкән урынга кадәр)<br>(ихтыяҗ булганда) |
| 2 | 2024 елның 19 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2025 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр | Бондаренко урамы буйлап ике якка да (С.Хәким урамындагы 3 номерлы торак йорттан С.Хәким урамына тоташкан урынга кадәр)<br>(ихтыяҗ булганда) |
| 3 | 2024 елның 19 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2025 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр | З.Солтан урамы (Ш.Мәрҗани урамыннан К.Насыйри урамына кадәр)<br>(ихтыяҗ булганда) |
| 4 | 2024 елның 19 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2025 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр | Ш.Мәрҗани урамы (Татарстан урамыннан Ф.Кәрим урамына кадәр)<br>(ихтыяҗ булганда) |
| 5 | 2024 елның 19 декабрендә 00.00 сәгатьтән 2025 елның 14 гыйнварында 00.00 сәгатькә кадәр | Кремль урамы (Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр) |
| 6 | 2024 елның 24 декабрендә 18.00 сәгатьтән 2024 елның 25 декабрендә 19.00 сәгатькә кадәр | А.Бичурин урамы (С.Хәким урамыннан Чистай урамына кадәр) |
| 7 | 2024 елның 24 декабрендә 18.00 сәгатьтән 2024 елның 25 декабрендә 19.00 сәгатькә кадәр | Мусин урамы (С.Хәким урамыннан Чистай урамына кадәр) |
| 8 | 2024 елның 24 декабрендә 18.00 сәгатьтән 2024 елның 25 декабрендә 19.00 сәгатькә кадәр | С.Хәким урамы (Әпсәләмов урамыннан Ф.Әмирхан урамына кадәр) |